**Дорогой подарок**

***Кадерле бүләк***

Бераз дулкынландыргыч та, бер үк вакытта гадәти дә көн иде ул. Табын артына барлык туган-тумачалар җыелган. Барысы да кызны туган көне белән тәбрик итәләр. Кыйммәтле бүләкләрнең, чәчәк бәйләмнәренең исәбе-хисабы юк.

Гадәттәгечә, табынны дәү әтисе ачып җибәрде:

- Яшәү дигән гомер чишмәсенең, милләтебез, рухыбыз чишмәсенең сулары саф килеш калсын, киләчәк буыннар алдында йөзебез ак булып калсын дисәк, тарихыбызны, кадерле ядкарьләр, изге мирасыбызны, нәсел шәҗәрәбезне барлау, туплау һәм саклау зарур. Нәни кызчыгым, мин сиңа нәсел шәҗәрәбезне үз эченә алган авыл шәҗәрәсен бүләк итәм. Өйрән, дәвам ит һәм күз караң кебек сакла!- диде дә, бер төргәк сузды.

Кызның куллары калтыранып китте. Бүләкне алуга ук түземсезлек белән кунакларның биергә киткәннәрен көтә башлады. Аның тизрәк дәү әтисе бүләк иткән әлеге төргәкне ачып карыйсы килде. Кызык бит! Нәрсә икән ул – мирас булып калырлык әйбер?!

Диана үз бүлмәсенә керде дә, кабаланып әлеге төргәкне чишә башлады. Ачса, исләре-акыллары китте. Бу бит... теге вакытта... Кызны хатирәләр дулкыны биләп алды.

- Дәү әтием, әйдә аулак өйдә икәү генә чәй эчеп алыйк әле.
- Әйдә, булмаса.

Диана дәү әтисенең болай тиз ризалашуына бик исе китте, әмма үзе чиксез шат иде. Ул яшен тизлеге белән табын әзерләде, күчтәнәч итеп алып килгән конфетларын куйды, мәтрүшкәләр салып чәй ясады.

Шулвакыт телефон шалтырады. Кыз йөгереп диярлек килеп, телефон трубкасын алды. Ул Г. Камал театрына “Шәҗәрә” спектаклен карарга киткән әти-әнисе шалтырата дип уйлады. Ә анда нининдидер абый дәү әтисе белән

сөйләшергә тели икән. Икәүләп чәй эчү хыялы тагын чәл- пәрәмә килерме икән инде? Хәер, дәү әтисе телефоннан озак сөйләшмәде, табын артына утырды.

- Дәү әтием, кем иде ул?
- Ул минем белән бертуган Камилә әбиеңнең улы Габдрахман абыең. Туганнан туган кардәшем була инде.
- Әллә кемнәр шалтырата сиңа, дәү әтием. Син барысы белән дә элемтәдә торасың.
- Шулай булмый ни. “Туганыңнан бизмә, нәселең корыр”, ди татар халкы, кызым. Тиздән Габдрахман абыең безгә киләчәк, - диде дә, ниндидер бер дулкынлану белән чәйгә үрелде. Аның үз-үзен тотышында үзенә бертөрле серлелек бар иде.

Бу икәве мәктәп хәлләре, ил яңалыклары турында гәп сатып, баллап-майлап чәй эчтеләр. Аннан бабасы үзенең эш бүлмәсенә кереп китте. Ә Диана исә, табынны җыештырды да, әкрен генә караңгылык пәрдәсе төшеп килгән шәһәр манзарасын күзәтергә балконга чыгып басты. Әле яңа гына унике яшен тутырып килүче тынгысыз йөрәкле кызга, дәү әтисенең үз-үзен тотышы һич тынгылык бирми иде. Менә инде ничә еллар бабасы үзенең эш бүлмәсендә ни беләндер мәшгуль. Әллә нинди борынгы кәгазьләр актара, кайсыларын күчереп ала. Бал корты кебек һич тынгылык белми. Бер карыйсың, суга балтасы төшкән кеше кебек, саргаеп беткән гарәп хәрефле кәгазьләргә карап уйга чумып утыра; икенче карыйсың, кош тоткандай канатланып йөри. Ә менә бүгенге телефон шалтыравыннан соң, ул бөтенләй башка. Бер үк вакытта куана да, кайгыра да кебек иде ул.

Шәһәр урамы әкренләп тынлыкка чума. Берәүләр кичке һава суларга урамга чыккан, икенчеләр ашыга-ашыга өйләренә кайтып бара, ә бала-чага дөньяларны онытып чыр-чу килә. Шул бихисап кешеләр арасыннан кызның игътибарын өстенә җиңелчә ак күлмәк, башына җәйге эшләпә кигән абый җәлеп итте. Абый дисәң, егетләр кебек бик ыспай киенгән, яшьләрчә җиңел атлый. Әлеге абзый Дианалар подъездына кереп китте. Кемгәдер кунакка бара, күрәсең. Кыз уйларын төгәлләргә дә өлгермәде, ишектә кыңгырау шалтырады.

Ачса, ишек катында әлеге абый басып тора. Кыз аптырап китте. Җиңелчә хәрәкәтле бу абзыйда, әтисе чалымнары бар кебек тоелды аңа.

Бу - дәү әтисе көткән кадерле кунак иде. Ул үзенең искереп беткән сумкасыннан бик пөхтә итеп төрелгән кәгазь чыгарды. Әлеге төргәкне чишеп җибәргәч, Диананың борынына музей, сандык исе килеп бәрелде. Нindидер зур агач рәсеме... Түгәрәкләргә кеше исемнәре дә язылган... Кыз моны ни дип тә юрарга белмәде. Ул сорау тулы күзләрен дәү әтисенә текәде. Ә ул исә, чал башын түбән игән, җыерчыклы яңаклары буйлап гәрәбәдәй күз яшьләре тәгәри.

- Мин бит моны күпме эзләдем, бу мизгелне күпме көттем, - диде дәү әтисе. Бераз сүзсез торганнан соң:
- Бу мин туып-үскән авылның шәҗәрәсе. Менә монысы безнең нәсел агачы. Монда син дә, синең әниең дә бар. Күр әле, никадәр кеше язмышы?! Күпме затлы нәсел?! Нинди генә танылган кешеләр юк бит алар арасында!.. Җырчы Зөфәр Хәйретдиновлар, танылган көрәшчеләр Зәһертдин Шәйхетдиновлар, Гайнетдин Садриевлар, очучы Гайнетдин Әхтәмовлар, гомумән, кемнәр генә юк монда...

Шул ук җәйне бабай оныгын үзенең туып-үскән авылына алып кайткан иде. Дәү әтисе уйнап йөргән кыр-болыннарны айкаганда, ялан тәпи чапкан балачак сукмакларыннан үткәндә кыз үзенең тамырларын нык сизде. Моннан искиткеч ял итеп, рухи ләззәт алып кайтты алар. Шуннан соң, һәр елны җәйге челләдә Питрәч районы Татар-Казысы авылына кайтып йөри торган булдылар. Бер кайтканда дәү әтисе: “Дөнья гел үзгәреп тора, үзгәрешләргә омтылып хәрәкәттә яши. Җир-суларның, урман-болыннарның, авыл-шәһәрләрнең, юлларның ни дәрәҗәдә үзгәргәнен бер буын эчендә дә абайлап була. Дөньяда бер генә нәрсә – Туган җирне ярату хисе, туган туфракка булган мәхәббәт кенә үзгәрешсез кала...” дигән иде. Әлеге сүзләрнең язучы Аяз Гыйлаҗевнеке икәнен кыз әле быел, язучының иҗаты белән танышкач кына белде. Шулай да, нинди галим, нинди искиткеч кеше бит аның ДӘҮ ӘТИСЕ!..

Кыз кинәт артына борылып карады. Анда ачык ишек яңагына сөялеп, булачак тарихчыны чал чәчле карт күзәтә иде. Оныгының зур кызыксыну белән

шәҗәрәне карап утыруы бабайның күңел кылларын тибрәндергән, күрәсең, керфекләрендә энҗе бөртекләре җемелди.

Диана дәү әтисенең кочагына атылды. Әйтерсең, бу мизгелдә тыйнак кына агып яткан ике инеш бергә кушылды да, зур агымлы елга хасил итте.

Якубова Наиля Габдрахмановна, г.Казань, республика Татарстан, Россия